# КАРАР
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлегенең Кече Мәрәтхуҗа авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

30 нчы ноябрь 2019 ел № 2

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 нчы елның 30 нчы ноябрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясе Кече Мәрәтхуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Кече Мәрәтхуҗа авылы зиратының керү капкасына кадәр юл салу;
- Кече Мәрәтхуҗа авылында кышкы чорда юлларны чистарту;
- Кече Мәрәтхуҗа авылында янгын гидрантларын урнаштыру;».

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 130 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 70 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 70 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенә керүче Кече Мәрәтхуҗа авылы халык җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясе Кече Мәрәтхуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Кече Мәрәтхуҗа авылы зиратының керү капкасына кадәр юл салу;
- Кече Мәрәтхуҗа авылында кышкы чорда юлларны чистарту;

- Кече Мәрәтхуҗа авылында янгын гидрантларын урнаштыру;» соравы буенча карарны кабул ителгән дип таныrга.

3. 2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясе Кече Мәрәтхуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

- Кече Мәрәтхуҗа авылы зиратының керү капкасына кадәр юл салу;

- Кече Мәрәтхуҗа авылында кышкы чорда юлларны чистарту;

- Кече Мәрәтхуҗа авылында янгын гидрантларын урнаштыру;».

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы урамы, 9 йорт;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов урамы, 9,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге
башлыгы: А.Г. Җиһаншин